Килешенде:
Өлкән тәрбияче
_______ Хөснетдинова Д.Р.
«29» _____08_____ 2023 ел

Раслыйм:
МБМББ «Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы» мөдире
_______ Габидуллина Э.С.
«29» _____08_____ 2023 ел

Каралды:
педагогик киңәшмә № 1
«29» _____08_____ 2023 ел

# Традицион булмаган алымнар кулланып балаларны сәнгати иҗат эшчәнлегенә өйрәтү буенча «Оста куллар» өстәмә белем бирү түгәрәге программасы

Реализацияләү вакыты 1 ел

Түгәрәк җитәкчесе: югары категорияле өлкән тәрбияче Хөснетдинова Д.Р.

2023 ел

## Эчтәлек


| | | |
|---|---|---|
| **1.** | **Максатчан бүлек** | |
| 1.1 | Аңлатма язуы | **2** |
| 1.2 | Актуальлелеге | **2** |
| 1.3 | Программаның максаты | **3** |
| 1.4 | Программаның бурычлары | **3** |
| 1.5 | Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр | **3** |
| **2.** | **Эчтәлек бүлеге** | |
| 2.1 | Программаның эш алымнары | **3** |
| 2.2 | Түгәрәккә кирәкле материаллар | **4** |
| **3.** | **Оештыру бүлеге** | |
| 3.1 | Перспектив план | **4** |
| 3.2 | Диагностика биремнәре | **8** |
| 3.3 | Кулланылган әдәбият | **9** |


## Аңлатма язуы

Мәктәпкәчә яшьтәге чор – баланың гомуми үсешенең нигезе. Нәкъ менә шушы чорда баланың төрле яклап үсешенә нигез салына.

Балада эстетик хисләр никадәр тирән, бай булса, матурлыкны күрә, аңлый белсә —бала матурлыкка чиксез шатлана. Гүзәллекне тоя белү кешене нәфисләндерә, рухи һәм әхлак ягыннан сафландыра, уйлау сәләтен үстерә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен сәнгати иҗат эшчәнлеге иң кызыклы эш төрләреннән санала. Аның аша балаларның иҗади мөмкинлекләре ачыла.

Традицион булмаган техника белән балаларны сәнгати иҗатка өйрәтү күп төрле материаллар һәм инструментлар кулланып башкарыла. Һичшиксез, бу техникаларны куллану балага да, олыларга да бик кызыклы. Бу алым белән эшләү балаларның фантазиясен үстерә.

## Актуальлелек

Бүгенге көндә, телевидениедә, хәтта балалар уенчыкларында да мәрхәмәтсезлек һәм агрессия күп очраган чакта, балалар үз эчләренә бикләнәләр, я булмаса балалар тискәре эмоцияләргә биреләләр. Нәкъ шуңа күрә бу программа белән шөгыльләнү мәктәпкәчә яшьтәге балаларның эмоциональ халәтләрен ныгыта, үз-үзләренә ышанычларын арттыра, балаларны төрле яклап үстерергә ярдәм итә. Шулай ук, кулның вак моторикасын үстерү өчен дә, логик фикерләүне үстерү өчен дә бик кулай. Программаның эчтәлеге кызыклы, балаларны рухи яктан бай шәхес итеп тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Программа төрле эшчәнлек төрләренә бай, һәр баланың матурлыкны күрү, тоя белү теләгеН канәгатьләндерлек итеп эшләнгән.

## Түгәрәк программасының максаты

Сәнгати иҗатның төп максаты — балаларны иҗат эшләре тудырырга өйрәтү. Әвәләп ясау кулларның вак моторикасы үсешенә булышлык итә, башкарылучы хәрәкәтләрнең төгәллеген үстерә, эш процессында балалар төрле материаллар, аларның үзлекләре белән танышалар. Аппликация конструкцияләү мөмкинлекләре үсешенә, форма, төс турында күзаллаулар формалаштыруга булышлык итә. Рәсем ясау кулларның катлаулы хәрәкәтләр эшчәнлеген, координациясен үстерүгә, мускулларын ныгытуга юнәлдерелә.

## Түгәрәк эшенең бурычлары

1. Төрле сурәтләү материалларына кызыксыну уятып, алар белән эшләргә өйрәтү.
2. Балаларны тукыма белән ябыштырып төрле образлар тудырырга өйрәтү.
3. Төсләр палитрасын үзләштерү өчен, балаларның коммуникатив эшчәнлеге өчен шартлар тудыру.
4. Сәнгати һәм иҗади сәләтләрен үстерү.
5. Иҗат эшенә кызыксыну уяту.

## Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр:

Балалар тасвирлау процессында билгеле дәрәҗәдә сәнгати иҗат эшчәнлегенең төрле төрләре белән танышалар, ясау күнекмәләренә өйрәнәләр.

Тирә – юнь турында белемнәре камилләшә, чөнки эшчәнлек төрле темаларга багышлана.

Бер эшне башкарганда төрле материаллардан куллана беләләр.

Төрле материаллар кулланып сурәтләргә, образлар тудырырга өйрәнәләр.

Иптәшләренең эшләренә ихтирам белән карап, үз эшләренә дөрес бәя бирергә өйрәнәләр.

## Традицион булмаган сәнгати иҗат эшчәнлегендә кулланыла торган алымнар:

Тукыма кисәкләре белән кисеп ябыштыру;
Табигый материаллардан куллану (агач күркәсе, җимешләр, яфраклар һ.б.);
Бармак бите белән эшләү алымы;
Пластилин белән эшләү алымы;
Табигый материаллар белән эшләү алымы;
Җепләр белән эшләү алымы.

Программа түбәндәге бурычларны хәл итүгә булыша:

- иҗади активлыкны, кул-бармак мускулларын, үз-үзеңне раслауга ярдәм итәргә ихтыяҗны үстерү.
- балаларны коммуникатив, интеллектуаль һәм сәнгати сәләтен үзләштерү процессында иҗатка өйрәтү.
- әйләнә-тирә мохитны уңай эмоциональ яктан үзләштереп, сәнгатькә кызыксыну мөнәсәбәте тәрбияләү.

## Түгәрәк эшчәнлеген оештыру

Түгәрәктә 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган балалар шөгыльләнә. Программа катлаулы темаларны 4 яшьлек балалар өчен җиңел вариантта бирүне күздә тота. Балалар эшчәнлеге көннең 2 нче яртысында атнага 1 тапкыр 30 минут дәвамында оештырыла.

***Түгәрәккә кирәкле материаллар:***
гуашь;
юеш салфеткалар (влажные салфетки);
су салу өчен стакан (непроливайка);
пластилин (16 төсле) һәм әвәләү өчен такта (+ доска для лепки);
төсле кәгазьләр (цветная бумага);
төсле картон (цветной картон);
ПВА клее (очлы борынлы – острым носиком);
Кайчы (ножницы);
клей һәм гуашь өчен пумалалар (кисточки тонкие и толстые – для клея и краски);
төрле тукыма кисәкләре (чуар һәм бер төстә) (лоскутки х/б, поплин, сатин – цветастые и однотонные);
төсле йон җепләр (цветные пряжи, нитки)
рәсем альбомы (альбом для рисования);
төрле табигый материаллар (бросовые материалы) – по необходимости.

### ***<u>Перспектив план</u>***

| Ай | № | Тема | Эшнең эчтәлеге һәм максаты | Кирәкле материал |
|---|---|---|---|---|
| октябрь | 1-2 | Түгәрәкнең максаты, бурычлары белән таныштыру. Карбыз ясау | Балаларны сәнгати иҗат төрләре белән таныштыру, аңа кызыксыну формалаштыру һәм кызыксынуларын үстерүне дәвам итү. Мөстәкыйль рәвештә кирәкле материаллар белән куллана белергә өйрәтү өстендә эшләү һәм аларга карата сакчыл караш тәрбияләү. | Альбом, пластилин, кипкән карбыз төшләре |
| | 3 | «Тәвә кошы» | Тукыма кисәкләреннән тәвә кошы кисеп-ябыштыру. Өлешләрне дөрес итеп урнаштырырга өйрәтү. Кошның матурлыгын күрергә өйрәтү. | Альбом, ПВА клее |
| | 4 | «Көзге агач» (Күмәк эш) | Кулларын кәгазьгә төшереп трафаретны кисеп ябыштыру. Кулларын (эчке ягын) гуашька манып кәгазьгә төшерү. Иҗади фикерләүләрен үстерү. | Ватман, ПВА клее, каен ботагы, төсле кәгазь, кайчы, гуашь, пумала |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ноябрь | 5-6 | Күлдә аккошлар (күмәк эш) | Нарат күркәләреннән пластилин ярдәмендә аккошлар ясау. Барысын да бер күлгә җыю. Табигый материаллардан пейзаж иҗат итәргә, матурлыкны күрергә өйрәтү | Табигый материаллар, пластилин |
| | 7-8 | Гөмбә | Альбом битен ясалган трафарет бунча төрле ысуллар һәм материаллар кулланып гөмбә ясау. Бизәү өлешләре өчен төрле ярмалар куллану. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү, үрнәк буенча эшләргә өйрәтү | Альбом бите, карабодай, манный ярмасы, кипкән яфраклар, карандаш |
| декабрь | 9-11 | «Өй» | Тукымадан җирлек ябыштыру. Уртага төрле геометрик фигура итеп киселгән тукымадан йорт ябыштыру. Матурлыкны күрә белергә өйрәтү. | Альбом бите, клей, пумала |
| | 12 | «Курчак» | Тукыма кисәгеннән җеп ярдәмендә курчак ясау. Курчакны ирекле бизәү. Иҗади эш төрләрен бпету | Тукыма кисәкләре, җеп |
| январь | 13 | «Күбәләк» | Җеп кисәкләреннән күбәләк канатларын, гәүдә өлешләрен ябыштыру. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтү. Җепне урап ябыштыру ысулын үзләштерү. Матурлыкны күрә белергә өйрәтү. | Альбом бите, җеп кисәкләре, кайчы, клей, пумала |
| | 14 | «Кунак табыны әзерләү» | Бизәкле салфетка кулланып кунак табыны әзерләү. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтү. Өстәл арты әдәбенә өйрәтү. | Альбом бите, тукыма кисәкләре, кайчы, клей, пумала, бизәле салфеткалар, пластилин |
| | 15-16 | «Карлыгач» | Тукыма кисәкләреннән болыт һәм кошны кисеп ябыштыру. Төсле җепләрне үреп салават күпере ябыштыру. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтү | Альбом бите, тукыма кисәкләре, төсле йон җепләр, кайчы, клей, пумала |
| февраль | 17 | «Чеби» | Төрле материал кулланып күкәй кабыгында утырган чеби ясау. Өслектә күз, авыз өлешләрен дөрес итеп урнаштырырга өйрәтүне дәвам итү. Матурлыкка соклану хисләрен | тукыма, төсле кәгазьләр, клей, пумала, пластилин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | уяту | |
| | 18 | «Ил сакчылары көненә этигә бүләк» | Табигый материал һәм картон кулланып вертолет ясау. Төсле кәгазь белән бизәү. Патриотик хисләр уяту | Альбом бите, төсле кәгазьләр, клей, пумала, табигый материал |
| | 19-20 | «Вазада чәчәкләр» әниләргә бүләк | Тукыма кисәкләреннән чәчәк өлешләрен, ваза кисеп ябыштыру. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Табигать матурлыгын күрә белергә өйрәтү | Альбом бите, тукыма кисәкләре, кайчы, клей, пумала |
| март | 21-22 | «Песи» | Тукыма кисәкләреннән песинең гәүдә өлешләрен кисеп, дөрес итеп урнаштырырып ябыштыру. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү, үрнәк буенча эшләргә өйрәтү. Матурлыкны күрә белергә өйрәтү | Альбом бите, тукыма кисәкләре, кайчы, клей, пумала |
| | 23-24 | «Ябалак» | Тукыма кисәкләреннән ябалакның өлешләрен кисеп, дөрес итеп урнаштырырып ябыштыру. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү, үрнәк буенча эшләргә өйрәтү | Альбом бите, тукыма кисәкләре, кайчы, клей, пумала |
| апрель | 25-26 | «Сирень чәчәге» | Тукыма кисәкләреннән бөкләп кисү юлы белән үрнәк буенча ябыштыру. Яз билгеләре турында белемнәрне ныгыту. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның иҗади омтылышларын хуплау. | Альбом бите, тукыма, клей, пумала |
| | 27-28 | «Вазадагы тал ботагы» | Пластилиннан ясалган озын таякчыклар (жгут) ярдәмендә тал ботагын, вазаны ясау, мамыкны бөтереп ясау юлы белән бөре ясау. Таякчыкларны түгәрәкләп борырга, ваза формасын алырлык итеп кыскалап урнаштырырга өйрәтү. Язның билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту. | Альбом бите, пластилин, мамык |
| май | 29-30 | «Каеннар» | Кәгазь кисәкләрен өзеп алу юлы белән үрнәк буенча каен агачлары рәсемен ябыштыру. Яз билгеләре турында белемнәрне | Альбом бите, төсле кәгазьләр, клей, пумала |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ныгыту. Каен агачының үзенчәлекләре турында сөйләшү. Альбом битендә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү | |
| | 31-32 | «Бәхетле балачак» | Альбом битенә кулларны төшереп төрле төсле пластилинны сылап ябыштыру ысулы белән бизәү. Һәр бармакка йөзләр ясау. Тукыма һәм йон җепләрдән чәчләр ясау. Гадәти булмаган рәсемдә матурлык тудырырга, аны күрә белергә өйрәтү | Альбом бите, пластилин, тукыма кисәкләре, кайчы, клей, җеп |

**Балаларның иҗади сәнгать эшчәнлегендә традицион булмаган ысуллар кулланып эшләү сәләтләрен ачыклау өчен диагностика биремнәре**

| № п\п | Бала ның исеме | Традицион булмаган ысулларны белүе | Традицион булма ган ысул ларның характер лы үзен-чәлекклә рен белүе | Фор ма ны бирү | Композиция | Хәрәкәт не күрсәтү | Төс | | Балл лар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Кәгазьдә эшне дөрес урнаш тыру | | Төсләрн ең ачы-луы | Төсләрн ең төр-лелеге | |
| 1 | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

***Эшчәнлек процессына анализ***:

**Югары дәрәҗә -** бала традицион булмаган иҗат алымнарына кызыксынып алына, теләк белән уенга кушыла. Традицион булмаган алымнарның характерлы үзенчәлекләрен белә. Теге яки бу алымны ни өчен сайлавын аңлата, алымны атый. Уйлаган эшен ачу өчен төрле эшләү алымын куллана. Тапшырылган эшне олылар ярдәменнән башка башкара.

**Уртача дәрәҗә**
Бала традицион булмаган иҗат алымнарына кызыксынып алына, бирелгән эшчәнлеккә теләк белән кушыла. Традицион булмаган иҗат алымнарының характерлы үзенчәлекләрен билгеләүдә ялгыша. Рәсемне урнаштырганда хаталар җибәрә.

**Түбән дәрәҗә**
Баланың традицион булмаган иҗат алымнарына кызыксынуы юк, бирелгән эш алымына теләк белән тотынмый. Иҗат алымнарының характерлы үзенчәлекләрен дөрес билгеләми, еш ялгыша. Тәрбияче ярдәменнән башка теге яки бу алымны ни өчен сайлавын аңлата алмый, алымны атамый. Эшен тулы биткә урнаштыра алмый.

3 балл – югары дәрәҗә
2 балл – уртача дәрәҗә
1 балл - түбән дәрәҗә

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. «Коллективное творчество дошкольников: конспекты занятий»./Под ред. Грибовской А.А.– М: ТЦ «Сфера», 2005. – 192с.
2. Соломенникова О.А. «Радость творчества». Развитие художественного творчества детей 5-7 лет. – Москва, 2001.
3. «Цветные ладошки» Е.Лыковой
4. «Ручной труд» под редакцией И.Климовой, Москва «Мозаика-Синтез, 2006г
5. «Чудеса для детей из ненужных вещей», М.И. Нагибина, Ярославль «Академия Развития», 1998г.
6. «Мозаика из круп и семян» Г.И. Перевертень, Издательство «Сталкер», 2006г.
7. «Поделки из природного материала»/авт.-сост. О.В. Белякова. – АСТ Москва, 2009г
8. «Аппликация из ткани»/автор-сост.С.С. Пискултга, . – Волгоград, 2015
9. «Поделки из природных материалов», И.Агапова, М Давыдова. Москва, 2006 г.
10. «Уроки ручного труда», А.В.Козлина., Москва, 2004 г.
11. Интернет ресурсы